**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Хуҗәмәт авыл җирлегенең Яңа Александровка торак пунктында
2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«26» ноябрь 2021ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлегенең Яңа Александровка торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2022 елда Хуҗәмәт авыл җирлегенең Яңа Александровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзсалым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. Яңа Александровка торак пунктында рус зираты коймасын урнаштыру (материаллар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

2. Яңа Александровка торак пунктында су алу скважинасына тирән насос сатып алу һәм урнаштыру(килешү буенча эш өчен түләү);

Әлеге карарны Хуҗәмәт авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга .http://menzelinsk.tatarstan.ru/хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Хуҗәмәт авыл җирлеге башлыгы:____________ Нургалиев И. Х.
(имза) (имзаның аңлатмасы)